*Май 2019*

# *Гимназия сулышы №4*

*25 нче гимназия укучылары газетасы*

***«Без  - бәхетле, без шагыйрьле халык,***
***Без – Тукайлы халык мәңгегә!»***



Яз җиттеме , без Тукай белән рухланып аңа табынып яши башлыйбыз. Бу табигый, чөнки аны безгә язлар алып килгән, язлар алып киткән. Үзенең аз гына ятим һәм бәхетсез гомерендә дә ул халыкчан, үлемсез һәм бәяләп бетергесез зур иҗатын калдырган. Шуңа да без аны олылап искә алабыз.

Татарстанда яшәгән  һәр татар кешесе  Габдулла Тукайның «Туган тел»ен яратып җырлый, «Су анасы», «Шүрәле» әкиятләрен сокланып укый. Г.Тукайны башка милләт халыклары да үз итә.Аның

шигырьләре дөньяның 15 теленә тәрҗемә ителгән. Сөекле шагыйребезнең шигырьләре, поэмалары, әкиятләре рус, казах, башкорт, үзбәк, инглиз, төрек, кытай, француз телләрендә яңгырый.
Хәйруллина Диләрә

**Шигырь бәйрәме**

Татар халкының сөекле шагыйре Габдулла Тукайның тууына 133 еллыгына багышлап гимназия китапханәсенәдә шигырь сөйләүчеләр бәйгесе үткәрелде. Гимназиянең 1-7 сыйныфлары укучылары Г.Тукайның шигырьләрен татар, рус һәм инглиз телләрендә сәнгатьле итеп, зур осталык белән сөйләделәр. 2 нче В сыйныфыннан Садыйкова Альмира курайда матур милли көй башкарды. 7нче Д сыйныфыннан Качаева Диана, Сивелькина Алинә дәртле җыр белән шигырь бәйрәменә килүчеләрнең күңелен күтәрделәр. Жюри бәйгедә катнашучыларны тыңлагач нәтиҗә ясады: 1 урынга 6 нчы Б сыйныфы укучысы Пшеворская Валерия лаек булды, 2 урын 1нче А сыйныфы укучысы Сираев Таһирга һәм 5 нче Г сыйныфы укучысы Кашипова Илонага бирелде, 3 урынны 6нчы Б сыйныфыннан Фазлыев Раил һәм 6нчы В сыйныфы укучысы Алексеева Регина алды.



Жюри әгъзалары исеменнән гимназиянең уку эшләре буенча директоры урынбасары Гарипова Рима Рөстәм кызы бәйгедә катнашучы укучыларның Г.Тукайның шигырьләрен сәнгатьле сөйләм осталыгын билгеләп үтте, барлык укучыларга зур рәхмәтен белдерде.
Баранкова Дана

**«Кванториум» - уңышлы киләчәккә илтә**



Түбән Каманың «Кванториум» технопаркы мәктәп укучылары һәм студентлар арасында елдан –ел популярлык казана, чөнки замана балалары яңалыкка омтылучан. Шундый кызыксынучан укучыларның берсе 8 А сыйныфы укучысы Рябов Григорий белән сөйләшүне газета укучыларга тәкъдим итәм.

- Мин роботлар белән кызыксынам, шуңа күрә инде «Кванториум»дагы робототехника түгәрәгенә йөрим. Быелгы уку елында Казанда мәктәп укучылары өчен World Scills чемпионатында катнаштым . «Кванториум»да ярты ел дәвамында промышленностьта эшләүче роботлар компетенциясе буенча программалар төзергә өйрәнгән идем. Бу конкурста мин 2 урынны алдым.

2018 елның апрелендә Мәскәүдә мәктәп укучыларының халыкара форумында катнаштым. Анда үзем шөгыльләнә торган юнәлеш буенча куп яңалыклар белдем.

Билгеле уңышларга команда белән бергә ирешәбез. Җәйге ял вакытында без



“Кванториум»да киләсе ярышка әзерләнәбез. Ноябрьдә сәләтле укучы буларак Анапада ял иткән идем, ә май аенда бер төркем укучылар Төркиянең Мармарис курорт шәһәрендә ял итеп кайттык. Ял өчен акча түләмәдек, тулысынча «Кванториум» технопаркы түләде.

_-Григорий, сиңа киләсе уку елында яңа уңышлар телим.

Бакирова Алия



**«Җиңү бәйрәме»н каршылап**

8 майда гимназиянең актлар залында 1941-1945 нче елларда Җиңү көненә багышланган тантаналы концерт булды. Тантанада катнашучы тыл һәм хезмәт ветераннарын микрорайон советы рәисе Пичугина М.Г. бәйрәм белән котлады  һәм Татарстан Президенты исеменнән бүләкләр тапшырды. Укучылар ветераннарга чәчәк бәйләмнәре бүләк иттеләр. Концерт  гимназия укучылары хоры башкаруында « Җиңү көне» җыры белән тәмамланды.

**Үлемсез полк**

Бөек  Ватан сугышы безнең илебездә кемнең генә гаиләсенә кайгы-хәсрәт алып килмәде икән? Илебез тынычлыгы өчен батырларча сугышкан, һәлак булган әтиләребезне, бабайларыбызны, ватандашларыбызны хәтеребездән чыгарырга тиеш түгел без.



«Үлемсез полк» россиякүләм акциясе дә нәкъ менә шул уңайдан, Бөек Ватан сугышында катнашкан туганнар турында хәтерне саклау чарасы.
Безнең  гимназия укучылары, укытучылары 9 май көнне бу акциядә катнашып, бабайларының, ватандашларының якты истәлеген хәтердә яңартты.
Садриева Эльмира

**Соңгы кыңгырау чыңлады**




23 май көнне 11нче һәм 9 нчы чыгарылыш сыйныф укучылары өчен «Соңгы кыңгырау» бәйрәме үткәрелде. Бәйрәмчә бизәлгән актлар залы укытучылар, укучылар һәм аларның әти-әниләре белән шыгрым тулы.



Унберенчеләрне котларга шәһәр мәгариф идарәсе башлыгы Фәретдинов Айдар Рафис улы килгән иде.

– Хөрмәтле чыгарылыш сыйныф укучылары! Сезгә бердәм дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырып, һәркайсыгызга үзегез теләгән уку йортына керүегезне телим, -диде ул.



Гимназия директоры Гаранина СветланаВладимировна үз чыгышында унберенчеләргә алдагы олы тормыш юлында үзләре куйган максатларына ирешүләрен теләде.

Бәйрәм унберенчеләрнең дәртле биюләре, моңсу җырлары, күңелле



интермедияләре белән үрелеп

барды. Сыйныф җитәкчеләре Илюкова Ирина Ивановна, Ибраһимова Эльмира Шәфиковна укучыларына матур теләкләр җиткерде.

Соңгы кыңгырау,
Олы юл көтә, көтә мең сынау!
Сау бул, хуш гимназия,
Сиңа бездән зур рәхмәт!

Минемчә, бу шигырь юллары унберенчеләрнең укытучыларга, гимназия хезмәткәрләренә карата булганзур ихтирам хисләрен белдерә. Якупова Гүзәл



***Кадерле газета укучыларыбыз! Менә 2018-2019 уку елы да ахырына якынлашты.***



***Шул уңайдан барлык укучыларны чын күңелдән котлыйбыз.***

***Чыгарылыш сыйныф укучыларына имтиханнарда зур уңышлар телибез.***



***Яңа уку елында кабат очрашырбыз. Күңелле җәйге яллар сезгә, дуслар!***



Редактор Якупова Г.

Проект җитәкчесе

Шарапова Н.Н.